**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1222**
**16.03.2020**

Башкарма комитетның 2010 елның 23 мартындагы 1808 номерлы карары белән расланган эш урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына электрон рәвештә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2010 елның 23 мартындагы 1808 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 18 октябрендәге 5458 номерлы карары редакциясендә) белән расланган эш урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезләмәгә, 4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«- хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яки кәгазьдә тиешенчә расланган яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эш бирүчедә булганда) белән имзаланган электрон документ рәвешендә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев